| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЛАР |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 12 августы**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 2147**

Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Кояшлы ур. 32 нче йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу турында

Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны гамәлгә ашыру максатларында "Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү турында" 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, Торак, Россия Федерациясе Җир кодекслары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Адресы: Васильево шәһәр тибындагы поселогы, Кояшлы ур., 32 нче йорт , - анда авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле 32 нче күпфатирлы торак йорт урнашкан. Шушы күрсәтелгән йортта беркетелгән исемлек (кушымта) нигезендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын (торак һәм торак булмаган биналар) алырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындаhttp://zelenodolsk.tatarstan.ruИнтернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен
   - сатып алына торган күчемсез мөлкәткә хокукка ия булучыларга;
   - күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга;
   - МКУ « Торак сәясәте департаменты»на җибәрергә.
4. МУ «Зеленодольск муниципаль районының Җир мөлкәте мөнәсәбәтләре палатасы»на әлеге карарның 1 пункында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

2016 елның 12 августындагы
2147 номерлы Зеленодольск
муниципаль районы Башкарма
комитет карарына кушымта

Васильево шәһәр тибындагы поселогы 32 нче күпфатирлы торак йортта урнашкан аварияле дип танылган һәм җимерелергә тиешле тартып алына торган күчемсез мөлкәт объектлары (торак, торак булмаган биналар)
Исемлеге

| №кв. |
| --- |
| 1 |